**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение**
**«Детский сад № 1 комбинированного вида» «Веселая карусель»**
**Чистопольского муниципального района Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы**
**«1 нче номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» «Веселая карусель»**
**мәктәпкәчә муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе**

# Отчет призера республиканского конкурса среди педагогических работников, осуществляющих преподавание на родном языке, на реализацию проектов, направленных на сохранение и развитие родных языков народов, проживающих на территории Республики Татарстан в 2024 году


*Гизатуллина Г.Г.,*
**воспитатель группы**
**с обучением**
**на родном татарском языке**


**Чистополь 2024 год**



**Гизатуллина Гульсина Гумеровна,**
***воспитатель группы***
***с обучением на родном татарском языке,***
***первой квалификационной категории***

**Уровень профессионального образования**

Высшее, ГОУ ВПО «Елабужский государственный педагогический университет», специализация «Татарский язык и литература с дополнительной специальностью русский язык и литература», квалификация «Учитель татарского языка и литературы, русского языка и литературы», 2010 год

**Общий стаж** 13 лет **Педагогический стаж** 13 лет
**Стаж в данной должности** 13 лет

**Профессиональная переподготовка**

по программе «Педагогика и психология дошкольного образования» в Институте экономики, управления и права (г.Казань), с 04.02.2013 по 10.06.2013г., 500 часов, диплом №841/2013

**Курсы повышения квалификации**

по программе «Реализация полилингвального образования в ДОО, в том числе 16 часов по особенностям организации работы с детьми с ОВЗ)», организованные в ГАОУ ДПО «Институт развития образования Республики Татарстан», 2022 год

**Почетная грамота** Управления образования Чистопольского муниципального района, 2013 год

**Благодарственное письмо главы** Чистопольского муниципального района Республики Татарстан, 2021 год


**Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение**
**«Детский сад № 1 комбинированного вида» «Веселая карусель»**
**Чистопольского муниципального района Республики Татарстан**

**Проект**
**«Путешествие к истокам родного языка»**
**«Туган тел чыганакларына сәяхәт»**

**Цель проекта -** формирование у воспитанников и их родителей стойкой мотивации к сохранению речевого наследия татарского народа путем пропаганды общения на родном татарском языке в образовательного учреждения и семьи

**Задачи проекта:**

-создать модель организации эффективного взаимодействия с родителями воспитанников на родном татарском языке через компоненты:


- организация культурно – просветительской деятельности (убедить родителей в необходимости общаться на родном татарском языке);
- погружение в культурно – образовательное пространство (организовать практическую работу с родителями по непосредственному общению на родном татарском языке присутствии их детей);
- знакомство с «Семейными правилами сохранения речевого наследия – правилами семи «П» (сформировать у родителей привычку использовать собственную речь на родном татарском языке как образец речи для детей).

-разработать серию конспектов календарных и событийных мероприятий по организации взаимодействия с родителями воспитанников и социальными партнерами с целью поддержания у всех участников образовательного процесса интереса к изучению татарского языка и общению на татарском языке.

-внедрить инновационные подходы в практику работы с воспитанниками и их родителями, способствующих языковому развитию всех участников образовательного процесса.

-обеспечить осуществление активного взаимодействия всех участников образовательного процесса (привлечение родителей и представителей социума к участию в проекте).(привлечение родителей и представителей социума к участию в проекте).

Модель организации эффективного взаимодействия
с родителями воспитанников на родном татарском языке



**Продукт проекта**

(серия планов конспектов календарных и событийных мероприятий на татарском языке по организации взаимодействия с родителями воспитанников и социальными партнерами)

**«Туган телем- иркә гөлем»-Халыкара туган тел көне бәйрәм кичәсе**

**Алдан әзерлек**: балалар белән туган як, туган тел турында әңгәмә үткәрү; шигырьләр, милли уеннар өйрәнү, халкыбызның элекке яшәеше турында сөйләшү, Г.Тукай, аның иҗаты турында белемнәрен ныгыту, туган як музеенда булу, читек бизәү.

**1нче алып баручы**: Исәнмесез, балалар!
Балалар: Исәнмесез!

**2 нче алып баручы**: Хәлләрегез ничек?

**Балалар:** Кояшлы көн кебек
Татар телен – Тукай телен
Өйрәнергә дип килдек.

**1.Бала**. Нинди ямьле көн бүген!
Йөгереп урамга чыктым.
Туган тел бәйрәменә
Бакчабызга ашыктым.

**2.Бала** Бакчабызда бүген бәйрәм,
Бәйрәмнең дә ниндие?!
Барыбыз да көтеп алган
Безнең Туган тел көне!

**1 нче алып баручы:**
Әйе, балалар, без бүген бик зур бәйрәмгә, халыкара туган тел көненә җыелдык. Безнең туган телебез – татар теле. Без туган телебезне зурлап татар телендә шигырьләр сөйләрбез, җырлар җырларбыз, татар халык уеннары уйнарбыз.
Туган оясыннан аерылган кош
Канатына мәңге ял тапмый.
Туган телен яратмаган кеше,
Башкаларның телен яратмый.

**2 нче алып баручы:** Балалар, 2000 нче елда Берләшкән Милләтләр Оешмасы, ЮНЕСКО инициативасын хуплап, күптеллелекне яклау йөзеннән 21 нче февральне «Халыкара туган тел көне» итеп үткәрү турында карар кабул итте.

Халкым теле миңа – хаклык теле.
Аннан башка минем телем юк.
Илен сөймәс кенә, телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк.

**3.Бала**. Дөньяда иң-иң матур ил
Ул минем Туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул минем туган телем.
«Балам!» –диеп, туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
«Әнием!» – диеп, әниемә
Мин туган телдә әйтәм.

**4бала** Туган телемдә сөйләшеп
Яшим мин Туган илдә.
«Туган ил» дигән сүзне
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам. (“Туган телем” Э.Мөэминова)

**5бала** Татар теле – минем туган телем,
Сөйләшүе рәхәт ул телдә,
Шул тел белән көйлим,
Шул тел белән сөйлим
Милләттәшем булган һәркемгә.

**6 бала** Дөньялар киң, анда илләр күп
Туган илем минем бер генә.
Туган илемдә дә телләр бик күп,
Туган телем минем бер генә. (“Татар теле” Н.Мадьяров)

**1 нче алып баручы:**

Безнең Татарстанда күп милләтләр яши. Һәр милләтнең үз туган теле бар. Чуашларның – чуаш теле, башкортларның – башкорт теле, русларның –рус теле. Ә татарларның – татар теле. Ә хәзер татарның милли уен коралы булган – курай моңын тыңлап китәрбез.

**1нче алып баручы:**
Ә хәзер башкорт уены уйнап алырбыз. Уен «Тирмә»

**2 нче алып баручы** Русча җыр тыңлап китәрбез.

**Жыр «Праздник»**

**7бала** Мы в любимом Татарстане
Дружно, весело живем.
По – татарски и по – русски
Мы танцуем и поем.
Веселиться вместе с нами
Всех друзей к себе зовём.

**8бала** «Бакчага килгәч» (Б.Рәхмәт)
Салкын кыш булса да, тышта кар яуса да,
Без өйдә ятмыйбыз, барабыз бакчага.
Безне бик яраталар бакчада апалар:
Килгәч тә елмаеп, кулларын киң җәеп,
Кочаклап алалар – әниләр күк алар.

**1нче алып баруч:**
Халкыбыз элек–электән тапкыр, зирәк булган. Тел турында мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар, мәзәкләр уйлап чыгарган.

**2нче алып баручы:**
Телебез турында бик күп мәкальләр бар. Хәзер сезнең белән бер уен уйнап алабыз.
Уен «Мәкальләр чылбыры»
Балалар, кулга кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Бер-берсенә туп биреп, мәкаль әйтешәләр. Бер бала мәкальне башлый, икенчесе дәвам итә.
Иң татлы тел – (туган тел, анам сөйләп торган тел.)
Сөйдергән дә тел, (биздергән дә тел.)
Теле барның (юлы бар.)
Телләр белгән – ( илләр белгән.)

Аз сөйлә – (күп эшлә.)
Акылы кысканың (теле озын.)
Сүзнең кыскасы, (бауның озыны яхшы.)
Туган илем – (туган анам.)
Аз сөйлә, ( күп бел.)
Тоз ашның тәмен китерсә, ( мәкаль сүз ямен китерә.)
Кем эшләми, (шул ашамый)
Тирләп эшләсәң, (тәмләп ашарсың)
Эш беткәч, (уйнарга ярый)
Калган эшкә ( кар ява)
Аз сөйлә, (күп тыңла)
Кунак булсаң, (тыйнак бул)

**1нче алып баручы:**
Балалар, бу мәкальләрдәге хикмәтле сүзләр безнең йөрәгебездә саклансын!

**9бала**. «Бакчабыз» (Ә.Кари)
Кояш чыккач, нурга чумгач урам, кырлар, яланнар,
Сөенеп бакчага киләбез: без бәхетле балалар.
Кичкә кадәр бу бакчада, эштә булгач әниләр,
Әниләр күк безне монда сөеп тәрбиялиләр.
Бакчабызда гөлләр үсә шау чәчәккә күмелеп,
Шул бакчада гөлләр кебек без үсәбез гөр килеп.
Ал бизәкле, гөл бизәкле, матур безнең бакчабыз,
Уйнап-көлеп, җырлап-биеп, анда күңел ачабыз.

**10 бала** «Бакчабызда бер бала бар…» (Л.Лерон)
Бакчабызда бер бала бар, шундый да ипле инде:
Кайчак, әбием әйткәндәй, бигрәк тәртипле инде!
Малайлар һәм кызлар белән бик әдәпле сөйләшә.
Үзендә булган тәм-томны барсына да өләшә.
Көчсезләрне кыерсытмый, рәнҗетми ул кызларны…
Ялгыш кына орынса да: «Гафу ит!» – ди, кызарып.
Уйнаганда ул һәммәсен көлдерә, шаккатыра.
Тәрбияче апабыз да гел аны мактап тора.
Ул баланың кем икәнен син белмисең, мин беләм:
Мактануны белми торган
Ул малай үзем булам!
Татар халык уены «Түбәтәй»
(Түбәтәй тукталган кеше табышмакка җавап таба)

Табышмаклар :
1. Кешенең дусты, йортның сакчысы (Эт)
2. Үлән ашый, май ташый (Сыер)
3. Алгы тәпие кыска, чабарга ул бик оста. Соры тунын сала да, ак тунын кия кышка (Куян)
4. Канаты бар, оча алмый, коры җирдә яши алмый (Балык)
5. Башы тарак, койрыгы урак, кычкыртып быргысын уята барысын (Әтәч)
6. Ул өстенә җәй дә, кыш та энәле күлмәк кия. Шулай да аны әнкәсе, йомшагым диеп сөя (Керпе)
7. Көлтә-көлтә койрыгым, селки-селки барамын, кетәклеккә кереп мин тавык-чеби аламын (Төлке)

**11бала** Татарчасы – туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң – анаң, әби –бабаң
Сине сөя торган тел.

**12бала**Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә безнең өчен
Иң кадерле тел.

**13 бала**.Туган тел – иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма,
Туган телне онытма!

**2нче алып баручы:**
Әйе, балалар, үз туган телеңне онытырга ярамый. Ә хәзер барыбыз бергә «Туган тел» җырын җырлыйбыз.
Җыр «Туган тел»

**«Авылда каз өмәсе» татар халык бәйрәме күренеше**

**Максат:** Балаларнын татар халык йолалары, бәйрәмнәре турында белемнәрен баету, татар фольклоры белән таныштыру. Каз өмәсе йоласы турында әнгәмә. Элекке гореф-гадәтлэрне искә төшерү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

**Жиһаз:** «Каз» йолкыр өчен тазлар, тастымаллар, бию өчен каурыйлар, утыргычлар, өстәл, самавыр, микрофон, компьютер.

Бәйрәм барышы: Бәйрәм уткәреләсе зал матур итеп бизәлгән. Авыл өе куренеше. Әкрен генэ музыка янгырый

**1 нче алып баручы:** Онытылган гореф-гадәтләрне
Яңартабыз хәзер көннән-көн
Уен йолалары,җыр-биюе
Һәр киләчәк көнне бизәсен.

**2 нче алып баручы:** Кыйгак-кыйгак,дия-дия,
Бәбкәләрне сөя-сөя.
Бөтен җиргә җитешергә
Ана казга туры килә.

Ширма артыннан ана каз булып киенгән тәрбияче як-ягына карана,карана каз кангылдаган авазлар чыгарып, залга чыга.Шул тавышка бер-бер артлы каз бәбкәләре (балалар) тезелешеп чыга.

**Уен «Ак казлар»**

**Алып баручы:** Менә шулай жил-давыл тидерми сакладылар казлар үз бәбкәлэрен. Матур язлар, ямьле җәйләр үтте. Үзенең муллыгы белән «Алтын көз» дә килеп җитте. Су буйларында йөргән бәбкәләр дә үсте. Авылларда «Каз өмәсе» башланды.

**Бала**: Көзге байлык! Көзге муллык!

Авылда каз өмәсе

Яше карты, бала - чага -

Шау-гөр килә һәммәсе! (кереп китә)

**Әби**: (уз-узенэ сөйләнеп керэ) И-и-и, бу эш дигәне гел бетми, һич кенә дә житешеп булмый. Аллага шөкер казып алган бәрәнгеләрне базга

урынлаштырдык, инде зур эшләрнен берсе генэ калып бара. Авылыбызда каз өмәсе дә бетеп килә, урамда су буеннан кайтучы казлар да кимеде. Алла боерса бүген чират бездә. Күрше кызларын да чакырдым. Озакламаслар, бик житез кызлар үсеп килә. (Ишектән тавыш ишетелә)

**1 кыз**: Исәнме,Күрше әби! Әллә казларыңны йолкып та бетерденме?

**Әби**: Исәнмесез, кызларым. Килеп тә життегезмени? Бик иртә кердегез әле.

**2 кыз**: Шундый матур көз иртәсендә йоклап ятып буламени, әбием.

Узең дә әнә барысын әзерләп куйгансын.

**Әби**: Әйе, кызым, суым хәзер кайнап чыга, сез кереп утырыша

торыгыз.Хэзер тәмләп чәй эчеп алырбыз.

**3 бала**: Чәй эчәргэ өлгерербез. Башта эшне бетерик.(Башка кызлар да ризалык белгертэлэр)

**Әби**: Алай булгач хәзер казларны алып кереп бирэм, йолка

башларбыз.(казларны балаларга бирэ).

Менэ сезгә казлар, жырлый-жырлый армыйча эшләгез.

**Әби**: Ә мин бәлешләремне әзерли торыйм.

**1 кыз**: Казларыгыз бигрәк матур

Таза булып ускәннәр

Ә йоннары, каурыйлары

Мамыкланып беткәннәр.

**Әби**: Аллаһы боерса, быел каз мамыгыннан гына мендәр ясыйм әле.

Яңа, йомшак мендәрдә йокы тәмле була ул.

(Урам якта капка тавышы ишетелә).

**1 малай**: Шыгыр-шыгыр капканы

Шыгырдатмый япмабыз.

Каз өмәсе булган жирдән,

Беребез дә калмабыз. (Керәләр)

**Малайлар бер-бер артлы**:

Исәнмесез, барыгыз

Бездән сәлам алыгыз.

**Әби**:. Мин бит курше егетлэрен узем чакырган идем. Онытмаганнар,

рәхмәт, килгәннәр. Үтегез, балакайларым .

**Жыр «Гармун уйныйм»**

**Әби:** Кызлар казларны йолкып бетерделәр инде.Кызлар, әйдәгез казларны монда куегыз. Курше әби эчләрен тазартканчы ,уйнап-җырлап алыйк. (Казларны өстәлгә, урындыкларын ян-якка алып куялар).

**Уен « Чума урдэк, чума каз»**

**Әби**: Балакайларым, казлар әзер, барыгыз су буена төшеп чайкап менегез.

(Казларны көянтәләргә элеп кутәрәләр , «су» буена төшәләр. Малайларга иләк белән каз каурыйлары бирелә. Алар түбәндәге сүзләрне әйтеп, каурый сибеп баралар).

**Малай**: Каурыйлары, каурыйлары

Сибелсен су буена

Казларыгыз шулай уңсын

Киләсе ел буена.

(«Су» буенда кызлар каз чайкыйлар).

(Кызлар туңдыра башлады бит әле, биеп алыйк булмаса диешәләр.

Казларны бәке читенә куеп бииләр).

**«Әйләнәбез түгәрәк»**

**Кыз**: Казларыбыз да чистарды. Җылынып та алдык. Әйдэгез, кайтабыз.

(Казларны алып түгәрәккә басалар. Музыка астында кайталар. Аларны әби

каршы ала. Түгәрәк эченә керә.)

**Әби**: Кайтып та җиттегезмени, балакайларым? Кая казларыгызны

алып куйыйм әле. Бигрәк уңган балалар булдыгыз. Мин әле бәлешләремне дә пешереп бетермәдем.

Кыз: Ярар, әби, борчылма, без уйный торабыз.

-«Самовар»лы уйныйк.

**Уен « Самовар»**

-Әйдэгез музыка коралларында үзебез яраткан «Хәтирә» көен уйнап алыйк.

**Музыка коралларында «Хәтирә» көен башкару**

-Түгәрәктэ биеп алыйк

**Тугэрэк бию « Ун ягымда дустым бар..»**

**Алып баручы** : Гөрләп үтте, шаулап үтте

Авылда каз өмәсе.

Бу айларны, бу көннәрне

Көтеп ала хәммәсе.

Менә шулай каз өмәсен

Татарда үткәргәннәр.

Ә яшь кызлар күңел биреп

Бу эшкә өйрәнгәннәр.

**Канатлар белэн бию «Каз канаты»**

**Әби:** Бәлешләрем дэ пеште, коймакларым да әзер. Әйдәгез, балалар бәлештэн авыз итик, каз майларына манып коймак ашыйк, чәй э

**«Әниемнең җылы кочагы» әниләр көненә багышланган кичә**

**Алып баручы:** Бүген җил дә йомшак исә,
Кояш та назлы көлә.
Бүген җиргә иң-иң якты
Кадерле бәйрәм килә.

Кадерле Әниләр! Сезне Әниләр бәйрәме белән тәбрик итәбез.

Бердәнбер иң кадерле, иң хөрмәтле, иң якын кешеләребез - Әниләр! Балаларыгыз турында гел яхшы сүзләр генә ишетеп яшәргә язсын Сезгә! Чөнки әниләр өчен моңардан да зуррак бәхет юк! Матур булсын, котлы булсын бәйрәмегез!

**1 нче алып баручы**: Әниләр бәхетле булсын өчен, баланың да бәхетле булуы кирәк. Без әниләрне рәнҗетмичә, аларга кайгы-хәсрәт китермичә яшәргә өйрәнергә тиеш.

**2нче алып баручы**:Без чыгышыбызны Сания Әхмәтҗанованың «Мин бәхетле булыр өчен тудым» дигән шигырен укып башлап җибәрәсебез килә.

Бу дөньга күпме кеше килгән,
Бардыр тагын күпме туасы.
Мин әнкәмнең Ходай сөеп биргән
Газизләрдән-газиз баласы.

Гомеремнең калын китабында
Булыр димим битләр ак кына.
Язмыш бит ул меңләп камчы суга,
Ә башлардан сыйпый чак кына.

Җил- яңгырлар тими үстем шул мин,
Давылларга ничек чыдармын?!
Ялгышып та,зинһар,рәнҗетмәгез,
Иркә гөлдәй юкса сулырмын.

Сөю-назга сусап туйганым юк,
Нәкъ нарасый сабый инде мин.
Бу дөньяга елар өчен түгел,
Көлеп яшәр өчен килдем мин.

Гомер китабымның соң битен
Тик елмаеп телим ябарга.
Мин бәхетле булыр өчен тудым
Һәм берәүнең бәхете булырга.

**1 нче алып баручы**: Безнең бүгенге бәйрәм уеннар формасында үтәчәк. Уеннарны бәяләү өчен жюри кирәк була. Жюри членнары белән танышып китик: ……

**1 Уен: Мәкальнең башы минем тел очында, ахыры кемдә икән?**

1. Ата йөрәге — таудан өлкән

Ана йөрәге-( диңгездән тирән.)

2. Ана күңеле балада,...(бала күңеле далада)
3. Ата-ананы тыңлаган –( адәм булган, тыңламаган — әрәм булган)
4. Бишектәге –(бишкә төрләнер.)
5. Әткәй — шикәр, әнкәй —( бал.)
6. Ана балага авызыннан (өзеп каптырыр.)
7. Ана яхшылыгын (авырсаң белерсең.)
8. Атаның каны, ананың (сөте)
9. Ана сүзен тотмаган, олыгайганчы ( игелек күрмәгән)
10. Яктылык – кояш янында, яхшылык – ( ана янында)
11. Ана куены ( туннан җылырак)
12. Баланың бармагы авыртса, ананың ( йөрәге авырта)

**2 нче алып баручы:** Әни җирдә иң газиз, якын кеше.Чөнки ул сине тудырган, күкрәк сөтен имезгән, җыр көйләп бишектә тирбәткән, беренче елмаюыңны күреп куанган, туган телне өйрәткән, халык моңын күңеленә сендергән... Әниләрнең сиңа кылган изгелеген санап бетерү мөмкинме соң?

**2 Уен: Бишек җырын башкару**

**1 нче алып баручы:** Нинди уңган безнең әниләр. Матур итеп бишек җырын да башкаралар. Әйе, алар бит шул җырларны җырлап нәни балаларын йоклатканнар, аларны үзләрен дә кайчандыр кадерле әниләре бишек җыры белән юатканнар.

**2 нче алып баручы:** Һәрбер хатын кыз бу дөньяда матурлыкны ярата, яисә инде гөлләр, чәчәкләр яраталар алар.Чәчәкләр бит алар матурлык бирүчеләр.

**3 Уен: Төсле битләрдән чәчәк ясау**

**Бала:** Чәчәкләрдән җем-җем итеп
Якты нурлар бөркелә.
Бүген минем дә әнкәмә
Рәхмәт әйтәсем килә.

**Алып баручы:** Хәзер кайсы бала әнисенә күбрәк матур сүз әйтә алыр икән шуны тикшерик әле. Башта битләргә язып чыгыгыз, аннан бер-бер артлы әйтеп барырбыз.

**4 Уен. Әниеңә матур сүзләр әйт.**

**1 нче алып баручы:** Күземнең төсләрен
Тәүге кат күрүче,
Өзелеп яратып,
Тәүге кат үбүче.
Тәүге кат сүземне

Ул гына ишеткән,
Рухыма, хисемә
Җылылык, нур сипкән.

**2 нче алып баручы**: Әни балага, бала әнигә кадерле. Үз балабыз өчен кайгырабыз, аңа иң яхшы теләкләр телибез. Әйдәгез әле, әниләр үз балаларыгызны табып карагыз. Сезнең күзләрегезне бәйлибез һәм сез балаларны кулларыннан тотып танырга тиеш буласыз.

**5 Уен. «Балаңны танып ал»**

**1 нче алып баручы:** Иң-иң сабыр, иң-иң тыйнак
Иң ягымлы кешеләр.
Иң сөйкемле , мәрхәмәтле
Алар безнең әниләр!
Әни сүзе – иң бөек сүз,
Юк аңа һичбер алмаш.
Иң-иң әйбәт кешеләр дә
Әни кебек булалмас.

**2 нче алып баручы:** Әни кеше бөтен һөнәргә дә уңган була. Үз эшен дә, ир-ат эшен дә оста башкара. Бала өчен аның газиз әнисе иң яхшы биюче, иң яхшы җырлаучы һәм бар яктан да иң-иң яхшысы. Хәзер безнең әниләр үзләренең осталыгын күрсәтеп китәрләр.

**6 Уен: «Иң оста биюче Әни»**

**Бала:** Әни безне тудырган, әни безне үстергән,
Ана сөте гомерлеккә җитә торган көч биргән.
Авырсаң янда тора ул, төне буе керфек какмый,
Үз саулыгын да кызганмый ул безне саклый-саклый!

**1 нче алып баручы:** Сезнең балаларыгызны үзегездән дә яхшырак белүче юк. Кая нинди яра, кая нинди миң дисеңме, күзенең төсе, борыны нинди, авызы нинди дип сорасалар да уйламыйча дөресен җавап бирәсез. Хәзер сез Әниләр, оста рәссамнар булмасагыз да, балаларыгызның рәсемен ясарга тиеш буласыз. Ә сез, балалар, Әниләрегезне сүрәтләгез.

**7 Уен: «Әниләр һәм балалар портреты»**

**2 нче алып баручы:** Галимәр баланың көнгә ничә сорау бирүе белән кызыксынганнар. Берничә ананың киеменә кечкенә микрофон һәм тавыш яза торган аппарат урнаштырганнар. Нәтиҗә: 4 яшьлек бала көнгә уртача 440 якын сорау бирә икән. Шулчаклы сорауга җавап кайтарып бетереп кара әле син!

**8 Уен: «Табышмакларга җавап тап»**

**Бала:** Тузаннарны сөртеп чыктым, коедан су китердем,
Әни эштән кайтканчы дип бөтен эшне бетердем.
Бүлмәләрне җыештырдым, бар җир ялт итсен әле!

Тик менә, ашарга гына пешерә белмим тәмле, җитмәсә бөтен ярмалар кушылган.

**9 Уен: « Ярмаларны аер».**

**Бала:** Мактаулы безнең әниләр
Данлы эшләре белән.
Әтиләр белмәгән эшне
Әниләр эшли белгән.
Наз гөлләре үсеп чыга
Сезнең җылы куллардан.
Кабул итегез котлаулар
Безнең ихлас җаннардан.

**Алып баручы:**Кадерле әниләр!
Бәйрәмегез сезгә бәхет,сәламәтлек китерсен,
Көнегез гел шат булсын!

**«Кояш гомере телим мин, әнием сиңа!»- 8 март бәйрәменә багышланган кичә**

**1 нче алып баручы:**

Кем дөньяга кеше бүләк итә?
Ә кешегә якты дөньяны.
Тойгылары кояш кебек кайнар,
Эретерлек гранит кыяны.
Кем куллары өйне, җирне ямьли?
Изгелеге үлчәү тапкысыз.
Ул әлбәттә яшәү чыганагы,
Тормыш яме ул- Хатын-кыз!

**2 нче алып баручы:** Хөрмәтле хатын-кызлар әбиләр, әниләр, апалар, кызлар, сезне барыгызны да шушы гүзәл бәйрәм белән тәбриклибез! Сәламәтлек ,ак бәхетләр юлдаш булсын сезгә!

Шушы бәйрәм көнегезне тагын да матурлап, нур өстәп балалар белән сезгә үзебезнең кечкенә генә бәйрәм күчтәнәчебезне бүләк итәбез.

**Бию «Йөрәкләр белән»**

**1 нче бала:** Язның беренче бәйрәмен,
8 Март диләр.
Бәйрәмегез котлы булсын.
Әниләр, кызлар, апалар.

**2 нче бала:** Күрәсезме, бүген кояш,
Ничек назлы елмая?
Әниемнең бәйрәмен,
Ул да бит көтеп ала.

**3 нче бала:** Безне назлап үстергәнгә,
Әниләр, рәхмәт сезгә!
һәрвакыт эшчән булганга,
Әниләр, рәхмәт сезгә!

**4 нче бала:** Йөзләрендә әни синең,
Гел шатлык булсын.
Көннәрең һәм бәйрәмнәрен,

Күңелле узсын!

**5 нче бала:** Ашлар тәмле булсын өчен,
Дөнья ямьле булсын өчен,
Гөлләр чәчәк атсын өчен,
Бәхет,шатлык атсын өчен-

**Бергә:** Әни кирәк! Әни кирәк!
Иң кадерле кеше җирдә.
Әни димәк!

**1 нче алып баручы:** Балалар башкаруында бик матур җыр «Рәхмәт әнием»
**«Рәхмәт әнием» җыр.**
**6 нче бала:**Поздравляю с праздником
Всех прекрасных дам.
Это значит: бабушек
И любимых мам!
Целый день сегодня
Буду помогать:
Я на стол накрою,
Застелю кровать,
Вымою посуду,
Дам вам отдохнуть.
И шалить не буду!
Разве что чуть-чуть.
**7 нче бала:**С папой мы давно решили
Маму в праздник удивить.
Мыли, гладили, варили
И, конечно, удивили,
Что об этом говорить!
Мама похвалила нас
И … уборкой занялась.
**8 нче бала:**Мөмкин булса, җыеп учларыма
Бирер идем кояш нурларын.
Әни кеше генэ кочагында
Назлый белә кызын, улларын.
Мөмкин булса, менеп зәңгәр куккә
Йолдыз сузар идем кулыңа.
Әни генә җан сулышын
Өрә синең гомер юлыңа.

**Жыр**: «**Яраткан бенең әни!**»
Балалар утыралар.

**2 нче алып баручы:** Безнен бүгенге бәйрәмебезгә әниләр генэ түгел, яраткан әбиләребез дә килгән.Без аларга да котлаулар әзерләдек.

**9 нче бала:** Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә әбием.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.

**10 нче бала:**Өйгә кайтсам,өй балкыган –
Өйгә нур иңгән.
Ерак җирне якын итеп.
Әбием килгән.
Үзен ничек сагынганны.
Белгән ул, белгән!
"Күрим әле улымны!" дип.
Әбием килгән.

**«Әбием – әбекәем» Җыр белән бию.**

**1 нче алып баручы:** Без матур кызларыбызны да онытмадык, аларга котлаулар һәм бүләкләр әзерләдек.

**11 нче бала:** Бүген кояш нурын сибә- сезнең өчен,
Тамчылар тама- сезнең өчен,
Кошлар сайрый- сезнең өчен,
Без дә шат елмаербыз- сезнең өчен!
Күңелле биюләребез- барысы да сезнең өчен!

**2 нче алып баручы:** Кадерле әниләребез, әбиләребез! Безнең балалар сезгә бүләккә бию әзерләделәр.

**«Күмәк татар биюе»**
**(дети после танца – Марьям, Аделя, Ясминя, Раяна, Ралина переодеваются на танец «Четыре попугая, котенок и щенок»,)**
**1 нче алып баручы:** Шигырьләр сөйләүне дәвам итәбез.
**12 нче бала:** Минем әни пәрәмәчне

Шундый тәмле пешерә,
Телеңне йотарсың малай
Ашап карасаң әгәр.
**13 нчебала:**Өчпочмакка җитми инде
Ни генә әйтсәгездә,
Әнием кебек берәүдә
Пешерә белмидер дә.
**14 нче бала:**Камыр тылсымга әйләнә
Минем әни кулында.
Кәнфит перәнник кирәк түгел
Гөбәдия барында.
**15 нче бала:** Кыстыбыйны бик яратам,
Бәлешне дә үз итәм.
Әнием кебек пешекче
Бар микән җирдә бүтән.
**16 нче бала:**Чәк-чәк белән торт ясарга
Минем әни бик оста
Тәмле-татлы ризыкларны
Әтием дә ярата.
**17 нче бала:**Мактанмагыз дусларым,
Иң оста минем әни.
Сумса, пилмән, шәңгәлләрне
Вәт пешерә билләһи!

**1 нче алып баручы:** Үзеңнең әниеңнән остарак, уңганрак, булганрак була алмый инде башканың әнисе. А хәзер без әниләр белән уйнап алабыз. Карарбыз кем тизрәк толымнарны үреп куяр икән.

**Уен «Заплети косичку»**

**1 нче алып баручы:** Безнең әниләр оста, әмма безнең балалар да оста, бии дә беләләр.

**Танец «Четыре попугая, котенок и щенок»**
**(девочки переодеваются в свои платья).**

**1 нче алып баручы:** Әниләргә багышланган шигырьләребезне сөйләүне дәвам итәбез.
**18 нче бала:**Кемнең әнисе иң әйбәт?
Минем әни, әлбәттә.

Өйрәтә әни мине дә
Әйбәт, матур гадәткә.
Үзе бөтен эшкә оста,
Мине өйрәтә җайлап.
Мактый, күңелне күтәрә
Иң кирәк сүзләр сайлап.
Иң чибәр әни минеке,
Толымнырын карачы.
Кояш кебек, нурлар сибә
Ягымлыкүзкарашы.
**19 нче бала:** А какой подарок маме
Мы подарим в женский день?
Есть для этого немало
Фантастических идей.
Ведь сюрприз готовить маме —
Это очень интересно…
Мы замесим тесто в ванне
Или выстираем кресло…
Ну, а я в подарок маме
Разрисую шкаф цветами,
Хорошо б и потолок…
Жаль я ростом не высок.
**20 нчебала:** Әниләрне тыңлагыз,
Яратыгыз, сөегез,
Җир йөзендә, иң кирәкле
Алар шуны белегез!
**21 нче бала:** Айдан, кояштан кадерле,
Син ул – әнием.
Иң ягымлы, иң сөйкемле,
Син ул – әнием!

**22 нче бала:**Встану утром рано,
Поцелую маму.
Подарю цветов букет-
Лучше мамы в мире нет!
**23 нчебала:** Пусть солнце светит для тебя,
Пусть цветут цветы,
Пусть сбываются всегда
Заветные мечты.
Сияй улыбкою своей

И будь счастливой самой!
С международным женским днем
Моя родная мама!

**2 нче алып баручы:** Әйдәгез әле балалар, әниләребезгә нинди ягымлы сүзләр әйтеп була?

**Уен «Кем күбрәк назлы сүзләр әйтә»**

**2 нче алып баручы:** Балалар, бигрәк матур сүзләр әйттегез. Әниләрегезнең дә күңелләре булгандыр.

**1 нче алып баручы:** Без сезне бик яратабыз,
Бәйрәм белән котлыйбыз,
Бүләк итеп үзегезгә
Бер матур бию биибез.

**«Әниләр белән бию»**

**2 нче алып баручы:** Ә хәзер кызык уеннар уйнарбыз.
1. «Үз балаңны таны».
2. «Коймаклар пеште».

**2 нче алып баручы:** Кадерле әниләребез, әбиләребез, кызларыбыз безнең малайлар да сезгә бүләккә бию әзерләделәр.

**«Малайлар татар биюен башкаралар»**

**24 нче бала:** Сезгә бүләк ясадык,
Иренмәдек тырыштык.
Үзең хезмәт куйган әйбер
Зур бүләк дип уйлаштык.

**1 нче алып баручы:** Әйе шул, үз кулларың белән ясаган буләк иң кадерле була. Балалар тырышып ясаган бүләкләрне әниләр кабул итегез.

**Буләкләр бирү.**

**2 нче алып баручы:** Җырсыз җирнең яме юк,
Җырсыз тормыш тәме юк,
Җыр сулап һава кебек,
Җыр яши, җыр мәңгелек.

**Җыр «Яз җитә»**

**1 нче алып баручы:** Кадерле әниләребез, сезгә ныклы сәламәтлек, сәламәт , тигез канатлы гаилә, гаиләләребездә һәрчак балаларыбызның менә шундый бәхетле, шат, сәламәт, иманлы, миһербанлы булуларына сөенеп кенә яшәргә насыйп булсын. Тагын бер кат бәйрәмнәрегез белән тәбрик итәбез.

**«Кояшлы язым» язны каршылау кичәсе**

Әкрен генә музыка ишетелә.
**Алып баручы**: Кадерле кунаклар һәм балалар! Бүген без иң матур бәйрәмне «Күңелле яз» бәйрәмен билгеләп үтәбез.

Көннәр аяз, күктә алсу.
Нур сибеп кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы-
Сагынып көткән яз килә.
Әйтегезче кайсы вакыт.
Яздагыдан ямьлерәк?
Көннәр җылы, күктә алсу.
Нур сибеп кояш көлә.
Җәйге шатлык, көзге бәхет.
Яз белән бергә килә.
Ә хәзер яз турында җыр башкарабыз.

**«Яз җыры»**

**1 нче бала:** Гөлләр, чәчәкләр тотып,
Тәмле хисләр аңкытып.
Тагын килеп җитте май-
Сагынып көтеп алган ай.

**2 нче бала:** Бүген бәйрәм булганга,
Бик күңелле урамда.
Күңелле шул бу бәйрәм.

Гөрләп тора зур мәйдан.

**3 нче бала:** Кошлар кайта каңгылдашып.
Казлар кычкыра.
Ә кояш көне буена.
Гөл көлеп тора.

**Яз керә.**

**Алып баручы:** Исәнме Яз кызы! Хуш киләсең безнең бәйрәмгә.

**4 нче бала:** Әй, Яз кызы, Яз кызы!
Хуш киләсең, уз бире.
Кунак булып килер диеп,
Күптән көттек без сине.

**5 нче бала:** Әй, Яз кызы,Яз кызы.
Хуш киләсең, уз бире.
Шатланышып җыр белән.
Каршылыйбыз без сине.

**6 нче бала:** Весна! Весна пришла опять!
С утра смотрю в окошко.
Я выхожу теперь гулять .
В резиновых сапожках.

**7 нче бала:** Ручьи бегут и тут и там,
В них солнышко искрится.
Грачи гуляют по полям,
Звенят в саду синицы.

**8 нче бала:**Весна! Как радостно дышать.
В саду у первых почек.
И в теплый день потом встречать.
Раскрывшийся листочек!

**9 нче бала:** Я не гуляю просто так,
Я радуюсь и знаю:
Весна приходит неспроста,
Я тоже подрастаю!

**Песня «А весной»**

**Алып баручы:** Яз кызы, безнең синең белән, берәр уен уйныйсыбыз килә.

**Яз Кызы:** Рәхәтләнеп уйнарбыз. Мин сезне сәяхәткә чакырам, әйдәгез әле поездга утырып барабыз.

**«Поезд» уены.**

**Яз кызы:** Кайчан – кайчан, кыр казлары.
Бак –бак – бак үрдәкләр,
Кара карга, карлыгачлар,
Сыерчыклар, тургайлар.
Бакча яме сандугачлар.
Урман күрке – күкеләр.
Барысы да кыш көнендә.
Җылы якта булганнар.
Язлар җиткәч, карлар киткәч.
Үлән чыккач, җир кипкәч.
Озак очып, диңгез кичеп.
Тагын безгә килгәннәр.

**Җыр «Сыерчык»**

**Яз:** Балалар, мин сезнең бәйрәмгә үземнең табышмакларымны да алып килдем.
Лампа түгел – яктырта, мич түгел – җылыта. (Кояш)
Агач бөгә – кулы юк, йөри торган юлы юк. Ачуланса – сызгыра, тузаннарны туздыра. (Җил)
Утта янмый, суда батмый. (Боз)
Борынсыз чыпчык боз тишә. (Тамчы)
Күктән килде, җиргә иңде (Болыт, яңгыр)
Ак ашьяулык таптым, җир өстенә яптым (Кар)
Исе юк, төсе юк, аннан башка тормыш юк. (Су)
Яз килсә, киенә, көз килсә, чишенә. (Җир)

**Алып баручы:** Яз кояшы күктән көлеп карый.
Яз кояшы ничек сөенгән.
Агачларда бәйрәм көткән кебек.
Яшел киемгә киенгән.
Шушы күңелле көндә.
Бию биибез без сезгә.

**«Разноцветная игра»**

**Яз:** Җир өстендә яткан карлар эреп бетсен.
Басуларда эш кайнасын.
Сез чыгарсыз бакчаларга шул көннәрдә.
Яшелчәләр утыртырсыз түтәлләргә.

**Алып баручы:** Яз кызы, яз кызы!
Безнең сөйгән кунак син.
Ямьле үтсен кичәбез,
Безне көлдерт, уйнат син.

**Уеннар: 1. «Сазлыктан үт»**
**2. «Шарикны түгәрәк буенча бер берсенә бирәләр, музыка туктауга кемдә шар,шул бала уртага чыгып бии».**

**Яз:** Минем күңелемне күрдегез,
Рәхмәт сезгә балалар.
Күп шигырьләр өйрәндегез,
Бии дә беләсез.
Хушыгыз, хуш дусларым.
Мин тагын килермен әле.
Яз килгәндә көтегез.
Телим мин сезгә бәхетнең зурысын.
Шатлыкның олысын.
Тәртипле булыгыз, бик матур торыгыз.
Ә хәзер миңа китәргә вакыт сау булыгыз, балалар.

**Гаилә елына багышланган кичә «Гаилә учагы»**

**1 нче бала:** Шатлыклар –күңелебездә,

Ал кояш-күгебездә.

Рәхәтләнеп бәйрәм итик-

Гаилә бәйрәме бездә.

**2 нче бала**: Бу кичәбез гөрләп үтсен,

Истә калсын гомергә.

Бәйрәмнәрсез яшәп булмый,

Җирнең якты йөзендә.

**3 нче бала** : Бәйрәмсез бик күңелсез бит,

Күңелсездер сезгә дә.

Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,

Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә

Кирәк һәммәбезгә дә.

**4 нче бала**: Бәйрәмнәр кирәк әтигә!

Бәйрәмнәр кирәк әнигә!

Бабай белән әбигә!

Бәйрәмнәр бик күп болай да

Барысы бергә.

Бәйрәмнәр булып торсын!

Бәйрәмнәр гөрләп торсын!

**1нче алып баручы**: Хәерле кич хөрмәтле әти – әниләр һәм бәйрәмгә килгән барлык кунаклар! Бүген без сезнең белән гаилә бәйрәменә җыелдык.

**2нче алып баручы**: Гаилә- ул тормышның нигезе. Әти-әни аның тоткасы булса, балалар гаиләнең көзгесе.Әгәр тотка купмасын, көзге ватылмасын дисәң, бер-береңне аңлап, хөрмәт итеп яшәргә кирәк.

**1 нче алып баручы** Гаилә ул- җылы учак.Гаилә никадәр нык булса, аннан килгән җылылык шулкадәр көчле була.

**2 нче алып баручы**: Гаилә ул- бик олы сүз. Әти-әни, әби-бабай- гаиләнең иң хөрмәтле кешеләре. Алар һәрвакыт безнең турында борчылалар.

**1 нче алып баручы**: Тату гаиләдә һәр кеше бер-берсен ихтирам итә, кайгырта. Шуңа күрә андый гаиләдә яшәве дә күңелле.

**2нче алып баручы**: Гаилә – дәүләтнең киләчәге. Матур гаилә корып, бер – береңне хөрмәтләп, бер – береңә ярдәмләшеп яшәү- һәрберебезнең изге бурычы. Безнең бүгенге бәйрәмебез дә юкка гына “Гаилә” дип аталмый. Тату гаиләләрдә генә тырыш, уңган, тәүфыйкълы, акыллы балалар үсә.

**1 нче алып баручы**: Гаиләнең ныклыгы, татулыгы нәрсәләргә бәйле. Хәзер мин сезгә шуларның берсе турында табышмак әйтәм, ә сез җавабын уйлагыз.

Кайвакыт ул мамык төсле йомшак,

Кайвакытта корычтай ул каты.

Кайчагында була баллы, татлы,

Ә кайчагында әремнән дә әче. (Тел).

**2 нче алып баручы**: Әйе, дөрес әйттегез, табышмакның җавабы-тел. Әгәр без ягымлы итеп сөйләшәбез икән, безнең турында йомшак телле диләр. Ә инде кырыс, дорфа итеп сөйләшүчеләрне әче телле диләр.

**1 нче алып баручы**: Йомшак, тәмле телле булганны һәркем ярата. Бер-беребезгә һәрчак ачык йөзле,тәмле телле, игътибарлы булыйк.Авыр сүзләр әйтеп, хәтерләребезне калдырмыйк, бер-беребезгә ягымлы булып, матур сүзләр генә әйтешеп яшик. Балаларыбыз тигез гаиләдә, сәламәт булып үссеннәр.

**2 нче алып баручы**: «Уйлап тап» уены.(Алып баручы берничә җөмлә әйтә, әниләр шул җөмләләрнең мәгънәсе буенча, сүзнең нәрсә турында барганлыгын әйтергә тиешләр).

1 нче бирем: -Ул барлык кешедә дә бар. Бер караудан туа, озак еллар яши. Ул кешеләрне шатландыра да, көендерә дә, сөендерә дә. Аннан башка яшәп булмый, олыгайган көннәрдә дә.(Җавап: ярату,мәхәббәт).

**1 нче алып баручы**: 2 нче бирем: -Ул бик кешенең бик матур чагы. Аны бигрәк әбиләр, бабайлар сагынып искә алалар.(Яшьлек).

**2 нче алып баручы**: 3 нче бирем: -Аны барлык кеше ярата.Ул бер дә искерми, гел яңара. Ул елата да, юата да, моңландыра да, арыганда ял иттерә.(Җыр).

**1 нче алып баручы** Бүген бездә күркәм пар канатлы, бер-берсеннән башка яши алмаучы,бер-берсен кайгыртып, яратып, шатлыкларын да, кайгыларын да бергә уртаклашып яшәүче иң матур гаиләләр кунакта. Ә хәзер инде сезне катнашучы гаиләләребез белән таныштырабыз.Сүзне гаиләләребезгә бирәбез.Алар алдан әзерләнгән визит карточкалары ярдәмендә, безне үзләренең гаиләләре белән якыннанрак таныштырырлар.

**2 нче алып баручы**:Хөрмәтле,күркәм гаиләләребез! Безнең бүген сезнең белән тагын да якыннанрак танышасыбыз, сезнең гаилә учагыгызның җылы нурларын башкаларга да өләшәсебез килә. Бүген бу сәхнә – сезнеке. Әйдәгез, рәхәтләнеп, бер күңел ачыгыз. Без сәхнәне сезгә тапшырабыз.

**I конкурс. «Таныш булыйк»**/Гаилә девизы,Гаилә турында презентация/

Һәр гаилә үз девизын әйтә, мәсәлән:

1. «Иңне – иңнәргә терәп

Әби – бабага кирәк

Балаларга без терәк

Булып яшәргә кирәк»

2.Картайганчы, тигезлектә

Бергә тормыш көтәргә.

Кайгыны да, шатлыкны да

Һәрчак уртак итәргә!

3.Алдашмаска, адашмаска,

Авырлыкта – ташлашмаска!

**1 нче алып баручы** *:*Әйе, шундый девизларга таянып яшәгән гаиләләр чынлап та күркәм була. Ә инде дөньяга уртак бала тугач, бу гаилә тагын да матурланып, тулыланып китә. Сабый дөньяга аваз салганчы ук, әти – әнисе аңа исем сайлый. Һәр исем нинди дә булса бер мәгънәгә ия.

**2 нче алып баручы:** Татар халкының бик үзенчәлекле бер традициясе бар. Ул – нәсел-нәсәбәңне белү, гореф-гадәтләрне буыннан-буынга күчерү, аның шәҗәрәсен өйрәнү. Боларны белмичә, туган җиреңнең, туган илеңнең тарихын белеп тә, өйрәнеп тә булмый. Моннан кала, гаилә ядкарьләрен кадерләп саклау, үз нәселеңнең абруе турында кайгырту да – фарыз гамәл. Өлкән буын вәкилләрен изге итеп тану, аларның яхшы эш-гамәлләре белән горурлану хас.

**<u>II конкурс. «Нәсел шәҗәрәсе»</u>**

«Балагызның исеме нәрсәне аңлата?» (*Һәр гаилә үз баласы исеменең мәгънәсен аңлата, мәсәлән: Булат – корыч кебек нык, таза, Камил – тулы, бөтен. Һ.б.Һәр гаилә нәсел шәҗәрәсе турында сөйли)*

**1 нче алып баручы:** Бала үсеп, тәүге адымнарын ясаганда, беренче сүзләрен әйткәндә, алар белән бик кызык хәлләр булгалый. Һәр гаиләнең күңел түрендә нинди дә булса кызыклы хәл саклангандыр. Шуларны искә төшерик әле.

**<u>«Бала белән булган кызыклы хәл»</u>** турында да сөйләп утегез әле

**2 нче алып баручы:**

**<u>III конкурс «Моңлы-сәләтле гаилә»</u>**

( Гаиләләр музыкаль сәләтләрен күрсәтәләр)

**1 нче алып баручы:**

**<u>IV конкурс «Гаиләм – табынлы түрем»</u>**

/Гаиләләр видео аша пешереп килгән бер милли ризыкны әзерләү һәм табынга бирү серләрен аңлаталар/

**2 нче алып баручы:** Милли ашлар турында табышмакларның җавабын табып карагыз әле:

Геометрик фигураны эченә алган милли ризык? (*Өчпочмак.*)

-Катлы – катлы татлы бәлеш? (*Гөбәдия.)*

-Туй табынының иң түрендә? (*Чәк – чәк.*)

-Ике сүздән торган милли ризык? (*Кош* теле.)

-Камырдан пешерелгән аш? (*Токмачлы аш.)*

-Эченә бәрәңге боламыгы салып пешерелгән ризык? (*Кыстыбый.*)

-Көн саен кирәкле ризык.Аннан башка аш үтми, аңа халык дан җырлый. (*Икмәк.*)

**1 нче алып баручы:**

**<u>V конкурс «Гаилә ядькаръләре»</u>**

(*Гаиләләр кадерләп саклана торган истәлек белән таныштыра)*

**2 нче алып баручы:** Гаиләнең ныклыгы, татулыгы күп нәрсәләргә бәйле.Ә сез гаиләдә матур итеп сөйләшә, бер – берегезгә тәмле сүзләр әйтә беләсезме икән, сынап карыйк әле!

Кайсы гаилә күбрәк матур сүзләр белә? (*Һәр гаилә чиратлап матур сүзләр әйтә, мәсәлән: 1 нче гаилә: «Матурым» , - ди. 2 нчесе – «Акыллым». 3 нчесе «Йомшагым», ди. Ахыргы гаилә матур сүз әйткәннән соң, 1 нче гаилә һәм башка гаиләләр уенны дәвам итәләр. Сүз таба алмыйча туктап калган гаилә уеннан «төшеп кала»)*

**1 нче алып баручы:**

**<u>VI конкурс. «Милли хәзинәләр»</u>**

**2 нче алып баручы:**

«Мәкальнең ахырын әйт**!**»

-Кем эшләми... (*шул ашамый.*)

-Беләге юан берне егар ... (*белеме булган меңне егар.)*

-Һөнәрле үлмәс ... ( *һөнәрсез көн күрмәс*.)

-Казаныңа ни салсаң ... (*кашыгыңа шул чыгар*.)

-Ана күңеле балада ... (*бала күңеле далада*.)

-Ата – ананы тыңлаган адәм булган ... (*тыңламаган әрәм булган.)*

-Атасына карап ... (*баласын коч*.)

-Оясында ни күрсә ...(*очканда шул булыр*.)

-Ата – анасына игелек күрсәтмәгән, олыгайгач үзе дә ... (*игелек күрмәс*.)

-Үзеңне үзең мактама ... (*кеше сине мактасын*.)

-Игелекле бала үстерсәң ... (*картлыгың бәхетле булыр*.)

5 нче бала.

Әти-әни! Сездән башка тагын,
Кем бар шундый бала бәгырьле.
Кояш җиргә бирәү булган кебек,
Сез дә безгә шулай кадерле.

6 нчы бала.

Безнең төркем балалары –

Әйтерсең бер гаилә.

Дус, тату, бердәм яшибез,

Күреп торасыз менә.

7 нче бала.

Күп белергә омтылабыз,

Матур җырлар җырлыйбыз.

Бию көе яңгыраса,

Ялындырып тормыйбыз.

**1 нче алып баручы:**

Бәйрәмебез ахырына якынлаша. Безнең әти – әниләргә, әби – бабайларга әйтер сүзебез бар. Бу нәниләр – безнең киләчәгебез. Аларны яратыгыз, мәрхәмәтле, тәүфыйклы итеп үстерергә тырышыгыз! «Тәүфыйкълы бала – бәхетле бала» дип, борынгылар юкка әйтмәгән. Ә балаларыбызга бәхетле булу өчен тагын нәрсә кирәк икән?

**2 нче алып баручы:**

| (*балалардан сорый*) | **Балалар**(*барсы бергә*): |
|---|---|
| -Җирдә сезгә ни кирәк? | - Әти һәм әни кирәк. |
| -Җирдә сезгә ни кирәк? | - Без яшәрдәй өй кирәк. |
| -Җирдә сездә ни кирәк? | - Туган үскән ил кирәк. |
| -Җирдә сезгә ни кирәк? | - Туган телебез кирәк. |

Әйе, хөрмәтле әти – әниләр, балаларыбыз дөрес әйтә. Туган теле булган халыкның гына киләчәге бар. Шуны онытмасак иде. Хөкемдарлар нәтиҗә ясаган арада туган телебезгә мәдхия җырлап алсак, бәйрәмебез тагын да ямьләнеп китәр.

**Барысы бергә басып «Туган тел» җырын башкаралар**

Нәтиҗәләр ясалганнан соң, гаиләләргә

«Иң зыялы гаилә», «Иң күркәм гаилә»,

«Иң тырыш» һ.б.шундый номинацияләр бирелә, бүләкләр тапшырыла.

**1 нче алып баручы:**

Көн артыннан көн туа. Кеше гомере аккан су кебек, искән җилләр кебек тиз генә үтеп тә китә. Бу дөньяда без яшибез икән, үзебездән соң калган буыннарга да әти-әнине олылау, туган җиребезне, туган телебезне, динебезне хөрмәт итү, табигатьне саклау кебек күркәм сыйфатларны, гореф-гадәтләрне яшь буынга түкми-чәчми тапшырырга мирас итеп калдырырга тиешбез.

**2 нче алып баручы:**

Бүгенге көн тормыш дисбесен тагын бер көнгә күчереп куйды. Кичәбездә алган кичерешләр һәркемнең күңеленә онытылмас истәлек булып кереп калыр, дип ышанабыз. Алдагы көннәрдә дә матур очрашулар, күрешүләр насыйп булсын!

**1 нче алып баручы:**

Гаиләләребезгә искиткеч соклануларыбызны белдереп, аларга чиксез зур рәхмәтләребезне җиткерәбез. Бәйрәмебезгә килеп, аны тагын да ямьләндергәнегез өчен, балаларыгыз хакына тырышканыгыз, үзегезнең гаилә традицияләрен саклый һәм яклый алганыгыз өчен рәхмәт сезгә!